**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет Азнакаевского муниципального района**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево, 423330
Тел./факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты**

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай шәһәре, 423330
Тел./ факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«__30___» ____12_____ 2025 ел.** **№ ___263___**

Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 елның 18 ноябрендәге 227 номерлы «2026 елга Азнакай муниципаль районы Физик культура һәм Спорт муниципаль учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган өстәмә түләүле хезмәтләргә тарифларны раслау турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Азнакай район Советының 2012 елның 28 маендагы 158-2 номерлы карары белән расланган Азнакай муниципаль районы муниципаль предприятиеләре һәм учреждениеләре товарларына, эшләренә һәм хезмәт күрсәтүләренә бәяләрне, тарифларны билгеләү Тәртибе, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы муниципаль предприятиеләре һәм учреждениеләре хезмәтләренә тарифларны (бәяләрне) карау буенча комиссия утырышының 2025 елның 25 декабрендәге 5 номерлы беркетмәсе нигезендә, карар бирә:

1. Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 елның 18 ноябрендәге 227 номерлы «2026 елга Азнакай муниципаль районы Физик культура һәм Спорт муниципаль учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган өстәмә түләүле хезмәтләргә тарифларны раслау турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- "Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының Физик культура һәм спорт идарәсе «МКУ халыкка 2026 елга өстәмә түләүле хезмәт күрсәтүгә тарифлар" кушымтасында Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының "Лидер" спорт мәктәбе " мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе бүлегендә:

түбәндәге эчтәлекле бишенче юлны өстәргә:

| № п\п | Хезмәт исеме | Бер айга абонемент 8 тапкыр (сум.) | Бер айга абонемент 4 посещения (сум.) | Тариф (бәя), 1 кешегә 1 сәгать өчен (сум) |
|---|---|---|---|---|
| 5 | 0 - 2 яшькә кадәрге балалар өчен «Сабыйлар йөзүе» (инструктор белән) | 3600 | 1800 | 500 |

2. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче А.Х. Шәмсетдинов